Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

# Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты

**Казан**
**2008**

# ЭЧТӘЛЕК

1. Гомуми белем бирү программаларының структурасына таләпләр.

2. Гомуми белем бирү нәтиҗәләренә таләпләр.

3. Гомуми белем бирү эчтәлеге (фундаменталь төш).

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАЛАРЫНЫҢ СТРУКТУРАСЫНА ТАЛӘПЛӘР

Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты- барлык төр белем бирү оешмалары өчен мәҗбүри саналган кагыйдә һәм таләпләрне үз эченә алган һәм укыту программаларының нигезен тәшкил иткән төп норматив-хокукый акт. Әлеге стандарт белем бирү процессының эчтәлеген яңарту, аның нәтиҗәләрен югары сыйфатлы итү максатын күздә тотып төзелде. Стандарт кысаларында татар теленнән гомуми белем бирү программаларының структурасына куелган таләпләр укыту процессында исәпкә алынырга тиешле төп моментларны берләштерә. Стандарт проекты белем бирү күләмен һәм дәрәҗәсен, татар теле буенча төзелгән программаларда татар теленең фундаменталь нигезен тәшкил иткән мәҗбүри белем бирү минимумында системалыкка һәм бертөрлелеккә ирешү юлларын билгели. Татар теленнән белем бирүнең дәүләт стандарты Татарстан Республикасындагы дәүләт аккредитациясенә ия булган барлык дәүләти, муниципаль һәм дәүләти булмаган гомуми белем бирү учреждениеләре өчен мәҗбүри. Ул төзеләчәк программалар өчен җирлек булып тора.

Татар телен укыту, укучыларның әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып, өч юнәлештә бара: татар мәктәпләрендә татар телен укыту, рус мәктәбендәге татар балаларына татар телен укыту һәм рус мәктәпләрендәге рус телле балаларга татар телен укыту. Әлеге юнәлешләр буенча төзелгән укыту программалары эчтәлеге, күләме ягыннан мәҗбүри белем бирү минимумыннан аерылырга мөмкин, әмма стандартта күрсәтелгән белем дәрәҗәсеннән түбән булмаска тиеш. Дәүләт стандарты нигезендә татар теленнән гомуми белем бирү программалары өч баскычка бүленә, һәрбер баскыч билгеле бер максатта төзелә, белем бирүнең мәҗбүри минимумына нигезләнә. Татар теле буенча гомуми белем бирү максатларына ирешү коммуникатив, лингвистик, этнокультура өлкәсенә караган компетенцияләр булдыру аша бара.

Тәкъдим ителгән стандарт проекты татар теле буенча гомуми белем бирү үзенчәлекләрен исәпкә ала.

Укыту программалары, дәреслекләр, методик кулланмалар эшләгәндә авторларга түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

- гомуми белем бирү баскычларының бәйләнешен саклаган хәлдә тел материалының күләме артырга мөмкин;
- күрсәтелгән тел материалын конткретлаштыру, детальләштерү; өйрәнеләчәк материалның логик бәйләнешле һәм педагогик нигезләнгән тәртибен билгеләү.

**Гомуми башлангыч белем бирү мәктәбе**

**(1 нче баскыч – I- IV сыйныфлар)**

Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирүнең максатлары:

- татар телендә аралашу күнекмәләре булдыру;
- тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә ейрәтү;
- тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
- сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы**

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) буенча укучыларда күнекмәләр булдырыла. Беренче баскычта укучылар укылган яки тыңланган текстның эчтәлегенә төшенә, темасын билгели ала, текст буенча әңгәмә үткәрә ала, гади план төзеп,

телнең орфографик һәм орфоэпик нормаларын саклап, телдән яки язмача эчтәлеген җиткерә, тексттагы җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап, сәнгатьле итеп укый белә, текстка үз мөнәсәбәтен белдерә һәм аны дәлилли. Тәкъдим ителгән темалар (үзе турында, гаилә, туган тел, туган ил, табигать, хезмәт, балалар тормышы, сәламәтлек, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр) буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештырырга сәләтле. Дөрес һәм матур язу күнекмәләрен үзләштерә. Төрле типтагы язма эшләр (диктант, изложение, сочинение) башкара. Көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен дөрес файдалана.

**Лингвистик компетенция**

**Татар теленең тармаклары** буенча **үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар:**

Хәреф һәм аваз турында төшенчә, татар теленең авазлары, аларнын язуда бирелеше, каллиграфик язылышы, татар алфавиты. Татар телендә сингармонизм законы. Иҗек, сүз басымы, хикәя, сорау, боеру җөмләләрнең интонациясе.

Сүз, аның лексик мәгънәсе. Сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Татар теленең сүзлек составы, аның килеп чыгышы. Лексикография.

Сүзнең мәгънәле кисәкләре, төрле сүз төркемнәрен ясый торган кушымчалар. Кушымчаларның ялгану тәртибе. Ясалышы ягыннан сүзләрнең төрләре.

Мөстәкыйль сүз төркемнәре (исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш), аларның төркемчәләре, төрләнеше һәм сөйләмдә кулланылышлары), бәйлек, бәйлек сүзләр, кисәкчә һәм теркәгечләр.

Сүзтезмә һәм җөмлә, җөмләдә сүз тәртибе. Гади җөмлә төрләре. Җөмлә баш һәм иярчен кисәкләре, тиңдәш кисәкләр, алар янында тыныш билгеләре.

## Этнокультура өлкәсенә караган компетенция

Дәреслекләрдә һәм өстәмә дидактик материалларда татар халкының милли гореф-гадәтләре, тарихы, мәдәнияте чагылган материаллар урын ала. Татар халык авыз иҗаты ядкарьләреннән табышмак, мәкаль-әйтемнәр, әкият, җыр, мәзәкләр белән таныштырыла.

## Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Татар теленнән гомуми төп белем бирүнең **максатлары:**

- укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам иту:
- укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, уз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;
- телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;
- татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;
- телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату; татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү.

Икенче баскычта татар теленең төп эчтәлеге өйрәнелә, укучыларга татар теле буенча системалы фәнни яктан ныклы белем бирелә, уку эшчәнлегенең төп төрләре формалаша ьәм үстерелә. Тәкъдим ителә торган материал татар теле тармакларының төп нигезен тәшкил итә. Белем бирүнең максатларын һәм үзенчәлекләрен истә тотып, программалар һәм дәреслекләр төзегәндә, материал күләме үзгәрергә мөмкин[1].

1. Рус телендә белем бирүче мәктәпләрдә түбәндәге үзенчәлекләр була: 1) аерым темаларны кыскартып бирү; 2) тел материалын өйрәткәндә гамәли кулланылышка йөз тоту; 3) рус һәм гатар телләрен чагыштырып өйрәнү.

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләм эшчәнлегевең төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) үзләштерелә. Икенче баскычта укучылар укылган яки тыңланган текстның темасы, төзелешен һәм төп фикерен, жанрын ачыклый, текст буенча әңгәмә үткәрә, үз фикерен дәлилли, телнең орфографик һәм орфоэпик, лексик, морфологик, синтаксик нормаларын саклап, телдән яки язмача эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып җиткерә. Телнең әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыра. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзи. Төрле типтагы язма эшләр, шул исәптән компьютер кулланып, (диктант, изложение, сочинение Һ.б.) башкара. Татар сөйләм этикеты нормаларын дөрес һәм урынлы куллана.

**Лингвистик компетенция**

**Тагар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар:**

Татар теленең иҗтимагый-мәдәни роле. Татар милли әдәби теле һәм аның төр орфографик һәм орфоэпик нормалары. Телнең фонетик системасы һәм аның закончалыклары. Иҗек, татар теленең иҗек калыплары. Басым, интонация һәм аларның төрләре. Орфография ьәм орфоэпия.

Сүз, аның лексик мәгънәсе. Сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Татар теленең сүзлек составы, аның ачык система тәшкил итүе. Сүзләрне килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм активлыгы ягыннан төркемләү. Фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре. Лексикография, сүзлекләрнең төрләре.

Сүзләрнең мәгънәле кисәкләре, аларның төрләре, сүз ясалыш ысуллары.

Мөстәкыйль сүз төркемнәренең лекеик-семантик ьәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләре, сөйләмдә кулланылышлары.

Сүзтезмә ьәм җөмлә, сүзләр һәм җөмләләр арасында бәйләнеш төрләре. Җөмлә кисәкләре. Җөмләләрне төркемләү принциплары. Туры һәм кыек

сөйләм. Текст, аның төзелеше. Татар телендә тыныш билгеләре.

Функциональ стильләр, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре. Сөйләм культурасы.

Җөмләгә һәм җөмләдәге сүзләргә фонетик, лексик, морфололик, синтаксик анализ ясау, сүзләрне төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерү.

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенция**

Тел чараларының халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәнү. Тәкъдим ителгән текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аеру, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен ачыклау.

**Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирү (10-11 сыйныфлар) баскычында белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы**

Татар теленнән гомуми урта (тулы) белем бирүнең **максатлары:**

•телне тулы бер система буларак күзаллау;

•татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасы турында мәгълүмат бирү;

•татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аңлаша белү;

•тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;

•текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;

•укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

Өченче баскычта укыту укучыларның татар теленең төп курсыннан алган белмнәргә нигезләнә һәм аларны системалаштыру, гомумиләштерүгә йөз тота. Өлкән сыйныфларда тел иҗтимагый күренеш һәм тамгалар

системасы буларак өйрәнелә. Татар теленең үсеш этаплары, төрки һәм европа телләре арасындагы урыны, бүгенге җәмгыятьтә телләрнең үзара мөнәсәбәте, керешүе өйрәнелә. Күрсәтелгән материалны программа һәм дәреслек авторлары, укыту максатларын күздә тотып, киңәйтә һәм тулылындыра ала.

## Коммуникатив компетенция

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) камилләштерелә. Укучы аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен дөрес, төгәл сайлап, иркен куллана, үз фикерен раслый һәм дәлилли. Төрле стиль ьәм жанрга караган текстлар төзи, тәкъдим ителгән текстларның тел үсешенең кайсы этабына каравын күзаллый, татар язуы үсешендә кулланылган язу үрнәкләрен аера, тормыш-көнкүреш, фәнни, рәсми эш стильләрен, алар га бәйле сөйләм этикеты нормаларын үзләштерә һәм гамәли куллана, гел-сурәтләү чараларын дөрес һәм төгәл кулланып, рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә ясый.

## Лингвистик компетенция

Татар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар:

“Сөйләм ситуациясе”, “әдәби тел”, “тел нормасы”, “сөйләм культурасы” төшенчәләре. Татар халкының язу тарихы, орфографик принциплар, орфоэпия. Татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик нормалары.

Лексикология фәненең тармаклары. Сүзнең лексик мәгънәсе, аның үсеш-үзгәреше. Татар теленең сүзлек составын төркемләү. Фразеологик әйтелмәләр, аларнын лексик мәгънәсе. Төрле типтагы сүзлекләр.

Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, татар теленең сүзлек составын баетуда сүз ясалышының толе.

Сүз төркемнәре, аларны төркемләү, сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте.

Синтаксисның төп берәмлекләре ,аларнын төрләре. Текст, текст берәмлекләренең үзара бәйләнеше.

Язма һәм сөйләмә тел, аларга хас үзенчәлекләр. Тел-сурәтләү чаралары.

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенция**

Телнең мәдәнияттән һәм тарихтан аерылгысыз булуына игътибар юнәлтү. Тел берәмлекләрендә, аларнын мәгънәләрендә миллилек чагылышын күрә белү, төрле телләрдә уртак төшенчәләрнең ьәм берәмлекләрнең кулланылыш үзенчәлеген, алар аша дөньяны танып белүдәге уртак һәм аермалы якларны ачу.

## 2. Белем биру нәтиҗәләренә (гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә) таләпләр

Татар теленнән белем бирү нәтиҗәләренә таләпләр укыту программаларында күрсәтелгән белем дәрәҗәсен үзләштерүне тикшерү максатын күз алдында тота. Укыту учреждениеләрендә алына торган белем сыйфаты ьәм аның эчтәлеге белән укучылар һәм ата-аналар танышырга бурычлы. Программалар үтәлмәгән очракта ата-аналар дәгъва белдерергә хокуклы.

Татар теленнән белем бирү нәтиҗәләре гомуми белем бирү системасының максатына туры китереп эшләнә һәм шәхси, иҗтимагый ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә йоз тота.

Дәүләт аккредитациясенә ия булган урта, махсус урта ьәм югары нөнәри белем бирү учреждениеләре чыгарылыш һәм кабул итү имтиханнарында бары тик стандартта каралган таләпләрне генә куя.

Татар теленнән гомуми белем бирү программаларын үзләштерүгә куелган таләпләр төрле дәрәҗәдәге гомуми урта белем бирү системасының горышын билгеләүдә, гомуми белем бирү учреждениеләрен һәм укытучыларны аттестацияләүдә нигез булырга тиеш. Белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы ьәм ана куелган таләпләр чыгарылыш сыйныф укучылары өчен дәүләт имтиханның үткәрүдә теп нигез була.

Татар теленнән белем бирү нәтиҗәләренә таләпләр укучыларның белем дәрәҗәсен, үзләштерергә тиешле күнекмәләрне, телне өйрәнгәндә кабул итә торган мәгълүматның үзенчәлеген, башка предметлар белән бәйләнешен.

телнең милли рухи һәм мәдәни мирас буларак, шәхес формалашуда ролен билгеләп, белем бирүгә таләпләр башлангыч, теп ьәм урта (тулы) белем бирү баскычларына аерылып бирелде,

**1 баскыч**

**Татар теленнән башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар графикасы үзенчәлекләрен, татар алфавитын белү;
- татар теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен аңлау;
  сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү;
- сүзнең мәгьнәле кисәкләрен аера белү;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен бер-берсеннән аера һәм аларныщ
  үзенчәлекләрен аңлата белү;
- сүзтезмә һәм җөмләне аеру, җөмләнең әйтү максаты буенча төрләрен аеру;
- җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аеру;
- авазларга, сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә, сүз төркемнәренә һәм җөмләгә өйрәнелгән күләмдә характеристика бирү.

**Татар теленнән башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында формалашырга тиешле күнекмәләр:**

- бирелгән җөмләләрне аңлап һәм дөрес итеп укый белү;
- 35-40 сүздән торган 9-11 җөмләле тестны дөрес итеп күчереп язу;
- фонетик, лексик, грамматик биремле күнегүләрне башкару;
- укылган (тыңланган) текстка карата сораулар куя белү, текст эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә алу;
- зур булмаган текстның эчтәлеген сөйләү;
- диалогик һәм монологик формада аралашу күнекмәләренә ия булу;
- төрле төрдәге диктант, изложение, сочинение язу;
- татар халык авыз ижаты әсәрләрен аера ьәм алардан мисаллар китерә

белү;

- көндәлек аралашуга бәйле татар сөйләм этикеты формаларын дөрес куллану;
- татар теленең орфоэпик нормалары нигезендә аралаша алу.

**Татар теленнән башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында укучыларга җиткерелә торган мәгълүматлар:**

- татар теленең башка телләр арасындагы урыны;
- телнең лексик ьәм грамматик чаралар байлыгы; лексик составның чыганаклары;
- аралашу даирәсенә карап сүзләрне сайлау мөмкинлекләре;
- төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләре, белешмәләр, электрон чаралар) белән эшләү.

**Татар теленнән башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында предметара эшчәнлек:**

- тел чараларының төрле жанрдагы әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен күрә белү;

тел материалын уку материалы белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт тәрбияләү;

- татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белү, сөйләм барышында ике тел чараларын бутамау;
- татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән лексик чараларны аеруга игътибар юнәлтү;
- татар теленнән алган белемне башка фәннәрне үзләштерүдә файдалана белү.

**Татар теленнән башлангыч белем бирү (1-4 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси үсеш-үзгәреше:**

- баланың физик ҺӘМ ПСИХИК сәламәтлеген саклау;
- укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту;
- тел аша әйләнә-тирә тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;
- укучыларның фикерләү сәләтен үстерү;

- баланың үзенә һәм башкаларга бәя бирүенә, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү.

**2 баскыч**

**Татар теленнән гомуми төп белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар теленең төп берәмлекләрен һәм ал арның билгеләрен белү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын, грамматик төзелешен үзләштерү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлау, бәйләнеш чараларын күрсәтү;
- җөмлә төрләрен аеру, алар яньщда тыныш билгеләрен куярга өйрәнү;
- текст төзелешен, текстның тел үзенчәлекләрен билгеләү;
- сөйләм стиле, фәнни, публицистик, рәсми-зш, матур әдәбият стильләрен аера белү...

**Татар теленнән гомуми төн белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында формалашырга тиешле күнекмәләр:**

- телдән һәм язма сөйләм, диалог һәм монолог, аралашу ситуациясе, тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны сәнгатьле итеп уку күнекмәләре булдыру;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача сөйләп бирү, текст буенча куелган сорауларга төгәл җавап бирү;
- бирелгән темага, куелган максатка яраклы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, тасвирлау яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерләү;
- текстның планын төзү яки эчтәлеген конспект рәвешендә язу;
- җөмләгә һәм җөмләдәге сүзләргә фонетик, лексик, морфололик, синтаксик анализ ясау, сүзләрне төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерү;

- гормыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әнгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу;
- сөйләү ьәм язуда татар әдәби теле нормаларын (орфографик, орфоэпик, лексик, грамматик, пунктуацион) саклау ҺӘМ сөйләм этикеты нормаларын үтәү;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә ьәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

**Татар теленнән гомуми төп белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында укучыларга җиткерелә торган мәгълүматлар:**

- татар теленең тулы бер система булуы, анын тармаклары;
- телнең лексик ьәм грамматик чаралар байлыгы, аларныя тел ситуациясенә бәйле үзгәреше;

  тел системасы, аның үсеш-үзгәреше, тел берәмлекләрен тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик мәгълүмат;
- төрле типтагы сүзлекләр һәм белешмәләр, электрон чыганаклар.

**Татар теленнән гомуми төи белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында предметара эшчәнлек:**

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләренең тәэсир көчен, сәягатьлелеген булдырудагы ролен ачыклау;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр ьәм халыклар арасындагы уртак хәзинә - рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле- ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;

  телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, анын үсеше турында күзаллау формалаштыру;

- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү.

**Татар теленнән гомуми төп белем бирү (5-9 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси үсеш-үзгәреше:**

- баланың акыл, мөстәкыйль фикерләү эшчвнлеген активлаштыру;
- баланың үзен тәрбияләү, үзе белән идарә итү, үз фикерен яклый алу сәләтен үстерү;
- сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлау;
- укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләренә, әхлак нормаларына төшендерү.

**3 баскыч**

**Татар теленнән гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч - 10-11 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрэжэсенә таләпләр:**

- телнен төп функциясен белү;
  татар әдәби теле тарихын, аның үсеш этапларын татар теленең үзгәреш тенденцияләрен белү;
- “сөйләм ситуациясе”, “әдәби тел”, “тел нормасы”, “сөйләм культурасы” төшенчәләренең мәгънәләрен аңлау;
- мәктәп курсында өйрәнелгән тел тармакларының система тәшкил итүенә төшенү;
- тел белеменә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, билгеләмәләрне белү;
- татар теленен төрле тармакларыннан алган мәгълүматка таянып, текстка лингвистик анализ ясау;
- телдән ьәм язмача бирелгән мәгълүматны үзләштерүнең төрле алымнарын файдалану;
- тел-сурэтләү чараларының үзенчәлекләрен аңлау һәм аларны лөрес куллану.

**Татар теленнән гомуми урга (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч - 10-11 сыйныфлар) баскычында формалашырга тиешле күнекмәләр:**

тормыш-көнкуреш, иҗтимагый- мәдәни, фәнни-уку, рәсми эш стильләрен, аларга бәйле булган сөйләм этикеты нормаларын үзләштерү һәм аларны гамәли куллану;

- татар әдәби теленең нормаларын (орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктуацион) белү һәм аларны телдән һәм язмача сөйләм процессында дөрес файдалану;
- тормыш-көнкүреш, фәнни, рәсми текстларны монологик һәм диалогик характерда, төрле жанрда һәм стильдә язу;
- тел-сурәтләү чараларын дөрес кулланып, төрле стиль һәм жанрдагы текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.

**Татар теленнән гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч - 10-11 сыйныфлар) баскычында укучыларга җиткерелә торган мәгълүматлар:**

- татар теленең тулы бер система булуын күзалларга ярдәм итә торган мәгълүмат;
- тел системасында барган тарихи-үсеш процессын ачыклый торган мәгълүмат;
- белем үзләштерүгә һәм тел берәмлекләрен тирәнтен анализлау өчен кирәкле өстәмә чыганаклар (фәнни хезмәтләр, белешмә әдәбият, электрон чаралар һ.б.);
- татар теленең төрки, рус, европа телләре арасында тоткан урынын һәм ролен бәяләргә ярдәм итә торган мәгълүматлар.

**Татар теленнән гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч - 10-11 сыйныфлар) баскычында нредметара эшчәнлек:**

- телнең рухи мәдәниятнең нигезе булуы, тел ярдәмендә рухи кыйммәтләрнең асылын аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү

чараларының үзенчәлекләрен ачу;

- татар телен рус теле белән бәйләп, телләрнең үзара бәйләныш-мөнәсәбәтләрен, шуд мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә уртак төшенчәләр һәм тел берәмлекләре барлыкка килүне аңлату;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, җәмгыять үсешенең телгә турыдан-туры мөнәсәбәте булуын җиткерү.

**Татар теленнән гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 иче баскыч - 10-11 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси усеш-үзгәреше:**

- укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләү эшчәнлеген активлаштыру, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау сәләтен арттыру;
- тормышның төрле өлкәләрендә телне дөрес, төгәл кулланып, фикер эзлеклелеге булдыру, тел зәвыгы тәрбияләү;
- тел материалы нигезендә татар халкы тарихына, милли, әхлакый сыйфатларга игътибарны юнәлтү, укучыларда горурлык, кешелеклелек, үз кадереңне белү кебек сыйфатлар тәрбияләү;
- татар теленең милли аһәңен, матурлыгын тоярга өйрәтү.

**Гомуми белем бирүнең эчтәлеге (фундаменталь төш)**

**Гомуми башлангыч белем бирү мәктәбе (I нче баскыч -IV сыйныфлар)**

**Коммуникатив компетенция**

**Тыңлап анлау.**

Сөйләмдәге сүз, сүзтезмә һәм жөмләләрне аңлау, аларны аера белү. Тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә төшенү, аның буенча сорауларга җавап бирү, әңгәмә үткәрү.

**Телдән сөйләм.**

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү, аерым темалар буенча әңгәмә кору. Укылган текстка сорау кую, аның эчтәлеген сөйләү, текстның планын төзү. Телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап, фикерне җиткерү; сөйләм этикеты үрнәкләреннән дорес файдалану.

**Уку.**

Башлангач сыйныфларга тәкъдим ителгән күләмдәге текстны анлап, орфоэпик нормаларны саклап, җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап, йогерек итеп укый белү. Текетнын темасын билгели алу. Гади план төзеп, текстның эчтәлеген сөйләү ьәм укучының текстка мөнәсәбәтен белдерүе.

**Язу һәм язма сөйләм.**

Фикерне, хәбәрне, укылган текст эчтәлеген орфография кагыйдәләренә нигезләнеп, грамматик дөрес язу,

**Лингвистик компетенция Фонетика. Графика. Орфоэпия. Орфографии.**

Хәреф һәм аваз турында төшенчә. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр.Тартык авазлар. Яңгырау һәм сангырау тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә хас үзенчәлекле авазлар. Татар телендә сингармонизм законы: рәт һәм ирен гармониясе.

Иҗек. Иҗек калыплары. Сүз басымы. Хикәя, сорау, боеру җөмләләрнең интонациясе.

Татар теленең теп орфо!рафик ьәм орфоэпик нормалары. 38 хәрефтән торган татар алфавиты. Хәрефләрнең каллиграфик яктан дөрес язылышы.

**Лексикология**

Сүз, анын лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр: Синоним, антоним ьәм омоним сүзләр. Татар теленең сүзлек составы. Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр.

Лексикография турында мәгьлүмат. Сүзлекләрне куллана белү.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр нәм кушымчалар. Төрле сүз төркемнәрен ясый торган кушымчалар. Кушымчаларның ялгану тәргибе. Тамыр һәм ясалма сүзләр. Кушма ьәм парлы сүзләр. Тамырдаш сүзләр.

**Морфология**

*Исем.* Исемнең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре.

Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. Исемнен сан, килеш, тартым белән төрләнеше.

*Сыйфат* Сыйфатның лексик-семантик ьәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Сыйфат дәрәҗәләре, аларнын дөрес язылышы һәм кулланылышы.

*Сан.* Саиның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Микъдар, тәртип, җыю саннары.

*Алмашлык.* Зат, сорау, күрсәтү алмашлыклары. Аларнын килеш белән төрләнеше. Алмашлыкларның сөйләмдәге роле.

*Фигыль.* Фигыльнең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Боерык һәм хикәя фигыль. Аларнын барлык-юклык, зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльнең хәзерге, үткән һәм киләчәк заман формалары. Фигыльне сөйләмдә дөрес куллану. Инфинитив.

*Рәвеш.* Рәвешнең мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылышы.

*Бәйчек һәм бәйлек сүзләр.* Баш, юнәлеш, чыгыш килешләрен таләп итә торган бәйлекләр, аларны сөйләмдә дөрес куллану.

*Кисәкчә.* Кисәкчәләрнең мәгънәләре , сөйләмдә кулланылышы.

*Теркәгеч.* Теркәгечләрнең төрләре, аларнын җөмләдә кулланылышы.

## Синтаксис

Сүзтезмә һәм җөмлә. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре һәм аларны дөрес интонация белән әйтү.

Тиңдәш кисәкләр, алар янында тыныш билгеләре.

## Этнокультура өлкәсенә караган компетенция

Татар халкының милли гореф-гадәтләре, тарихы, мәдәнияте. Татар халкының мәкалъ-әйтемнәре, табышмаклары. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре, матур әдәбият әсәрләреннән милли үзенчәлекне чагылдырган лексик берәмлекләр. Көндәлек. аралашуга бәйле татар сөйләм этикеты нормалары.

**Гомуми тон белем бирү мәктәбе**

**(2 нче баскыч - У-1Х сыйныфлар)**

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Телдән сөйләм һәм язма сөйләмне аеру, аралашу өлкәсенә һәм сөйләм ситуациясенә бәйле алардав дөрес файдалана белү. Диалогик һәм монологик сөйләм. Иҗтимагый-мәдәни, әхлакый, көнкүреш темаларына бәйле монологик һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү. Тел берәмлекләрен сөйләм ситуациясенә бәйле аера белү.

Танышу, өйрәнү, эзләнү', карап чыгу максаты белән уку төрләрен үзләштерү. Китаплар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет ь.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.

Сөйләм эигчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.

Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә бирү. Аралашу процессында татар әдәби теле нормаларын дөрес куллана белү.

Текстның темасы, төзелеше һәм төп фикере. Аларның стиль һәм жанр төрлелеге. Текст эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып сөйләү. Диктант, изложение, сочинение язу. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект ь.б.).

**Лингвистик компетенция**

**Тел турында гомуми мәгълүмат**

Телнең кеше тормышында ьәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле-Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар милли әдәби теле. Татар әдәби теленен нормалары. Хәзерге татар теле лексикасының ачык система булуы.

**Фонетика. Графика. Орфоэпия. Орфография**

Хәреф һәм аваз мөнәсәбәте. Сузык һәм тартык авазлар, аларны белдерә торган хәрефләр. Авазларны төркемләү. Авазларның сөйләмдәге үзгәреше. Татар теленең фонетик закончалыклары. Ижек. Иҗек калыплары. Басым, аның төрләре. Сүз басымы, анын үзенчәлекләре. Интонация ьәм аның

өлешләре. Татар әдәби теленең әйтелеш нормалары.

Татар теленен төп орфографик һӘМ орфоэпик нормалары. Тагар орфографиясенең кыен очраклары.

## Лексикология

Сүз, аның лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. Синоним, антоним һәм омоним сүзләр. Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы. Кулланылыш даирәсе ягыңнан татар,тёленең сүзлек составы. Кулланылыш активлыгы ягыннан татар теленең сүзлек составы. Фразеологик әйтелмәләр. Хәзерге татар әдәби теленең лексик нормалары. Төрле типтагы сүзлекләр, алардан файдалану.

## Сүз төзелеше ьәм сүз ясалышы

Морфемика. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр. Кушымчалар, аларның төрләре: сүз ясагыч кушымчалар, мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар.

Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларның төрләре: бәйләгечләр (исемдә - килеш, тартым, хәбәрлек, фигыльдә - зат-сан); модаль мәгънә белдерүче кушымчалар (фигыльдә - заман, юнәлеш, фигыль төркемчәләре күрсәткечләре, юклык, исемдә - күплек, стилистик, сыйфатта - дәрәҗә, сан төркемчәләре). Кушымчаларның ялгану тәртибе. Нигез (сүзнең тамыр һәм сүз ясагыч кушымчадан торган өлеше).

Татар телендә сүз ясалыш ысуллары (кушымчалау ысулы; сүзләр кушылу ысулы; бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү ысулы; сүзләрне кыскарту ысулы; фонетик ысул; сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү ысулы).

## Морфология

Татар теленең сүз төркемнәре системасы. Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре. Бәйләгеч сүз төркемнәре: бәйлек, теркәгеч. Модаль сүз төркемнәре: ымлык, кисәкчә, модаль сүзләр.

*Исем.* Исемнең лексик-семантик һәм морфологик-сиптаксик үзенчәлекләре. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. Исемнең сан, килеш, тартым белән төрләнеше. Исем ясалышы.

*Сыйфат.* Сыйфатның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат дәрәҗәләре, аларның дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатның исемләшүе. Сыйфат ясалышы.

*Сан.* Санның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Сан төркемчәләре. Санның исемләшүе. Сан һәм саналмыш мөнәсәбәте. Сан ясалышы һәм дөрес язылышы.

*Алмашлык.* Мәгънәви төркемчәләре. Аларның кулланылыш үзенчәлекләре. Алмашлыкларның сөйләмдәге роле. Алмашлык ясалышы.

*Фигыль.* Фигыльнен лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр, аларга хас грамматик категорияләр. Ярдәмче фигыльләр. Аналитик нигезле фигыльләр, аларның белдергән мәгънәләре. Фигыльнең сөйләмдә кулланылышы. Фигыль ясалышы.

*Рәвеш.* Рәвешнең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Рәвеш төркемчәләре. Рәвешләрнең дәрәҗә формасы алуы. Рәвешнең җөмләдә кулланылышы. Рәвеш ясалышы. Рәвешләрдә басым төшү үзенчәлеге.

*Бәйчек һәм бәйчек .сүзләр.* Бәйлекнең грамматик мәгънәсе һәм синтаксик функциясе. Сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. Бәйлек сүзләр.

*Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр.* Төркемчәләре. Аларның сөйләмдә кулланылышы. Теркәгечләрнең дөрес язылышы.

*Ышык.* Төркемчәләре. Сөйләмдә кулланылыш үзенчәлеге.

*Кисәкчә.* Төркемчәләре. Сөйләмдә кулланылышы. Дөрес язылышы.

*Модаль сүзләр.* Мәгънәсе. Сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре.

**Синтаксис. Пунктуация**

Сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзләр һәм җөмләләр арасында бәйләнеш төрләре. Җөмләләрнең әйтү максаты ягыннан төрләре, аларны барлыкка китерә торган чаралардан интонация, логик басым һәм сүз тәртибе. Җөмләнең грамматик нигезе. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Тиңдәш кисәкләр.

Гади ьәм кушма җөмлә, аларнын төрләре. Эндәш һәм кереш сүзләр. Кереш җөмләләр. Туры һәм кыек сөйләм. Текст, аның төзелеше. Хәзерге татар әдәби теленең синтаксик нормалары.

Җөмлә ахырында, тиңдәш кисәкләр янында, гади һәм кушма җөмләләрдә, диалог һәм монологларда, цитаталарда тыныш билгеләренең куелышы.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы**

Стиль төшенчәсе. Язма сөйләмнең функциональ төрләре. Аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре. Сөйләм культурасы. Әдәби сөйләмгә хас төп билгеләр. Сөйләмдә лексик чараларның (синонимнар, антонимнар, калькалар, фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр) кулланылыш мөмкинлекләре.

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенция**

Татар теленен башка телләр арасында тоткан урыны. Телебездә халык мәдәнияте, тарихы чагылышы.

Халык авыз иҗаты җәүһәрләре. Халык авыз иҗаты, матур әдәбият әсәрләрендә, тарихи вакыйгаларны чагылдырган текстларда милли-мәдәни кыйммәткә ия булган берәмлекләр, аларнын мәгънәләре аңлатмалы, этимологик, тәрҗемәи һәм башка сүзлекләрдә бирелеше.

Төрле өлкәгә караган татар сөйләм этикеты нормалары, халкыбызның аралашу культурасы үзенчәлекләре.

**Гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе**

**(3 иче баскыч — X-XI сыйныфлар)**

**Коммуникатив компетенция**

Сөйләмдә аралашу өлкәләре һәм ситуацияләре. Аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләре. Сөйләм эшчәнлегенен барлык төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) камилләштерүне дәвам итү...

Аралашуның төрле өлкәләренә караган диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Төрле характердагы текстларны укып анлау, төп мәгълүматны дөрес кабул итү. Төрле стиль һәм жанрга караган текстлар төзү *.

Йолдызчык (*) белән татар мәктәпләре ьәм рус мәктәпләрендәге татар балалары үзләштерергә тиешле материал күрсәтелде.

Функциональ стильләр һәм аларның үзенчәлекләре.

Фәнни һәм рәсми аралашуның телдән һәм язма формаларын куллану. Доклад, реферат, тезис, бәяләмә, ышаныч кәгазе резюме кебек төрле жанрдагы эш кәгазьләрен язу күнекмәләрен камилләштерү.

**Лингвистик компетенция**

**Тел турында гомуми мәгълүмат**

Телнең иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы булуы. Аның төп функцияләре.

Төрки телләр һәм татар теле. Татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Татар диалектлары. Татар әдәби теле, аның нормалары һәм сөйләмдә алардан урынлы файдалану. Икетеллелек һәм күптеллелек.

Төрле жанрда язылган текстларга лингвистик анализ ясау*.

**Фонетика. Графика. Орфоэпия. Орфография**

Татар теленен фонетик, график, орфографик, орфоэпик нормаларын үзләштерүне дәвам итү. Татар халкының язу тарихы (рун, уйгыр, гарәп, латин, кирилл алфавитлары). Орфографик принциплар, орфографиянең кыен очраклары.

Татар орфоэпиясе. Әйтелеш һәм язылыш арасында аерма булган очраклар, әдәби әйтелешне бозу очраклары һәм сәбәпләре.

**Лексикология**

Лексикология фәне, анын тармаклары турында мәгълүмат. Сүз, анын мәгънәсе. Татар теленен сүзлек составы һәм андагы үзгәрешләр. Килеп чыгышы ягыннан татар теленен сүзлек составы. Кулланылыш даирәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Кулланылыш активлыгы ягыннан татар теленең сүзлек составы. Фразеологик әйтелмәләр, аларның лексик мәгънәсе. Фразеоллогик әйтеләмәләрнен төрле стильләрдә кулланылышы һәм сөйләмдәге вазифалары*. Төрле типтагы сүзлекләр, алардан файдалану.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы**

Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Сүз төзелеше. Сүз ясалыш ысуллары. Сүз һәм форма ясалышын аеру.

## Морфология

Татар телендә сүзләрне төркемләү принциплары. Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат-.' сай, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре. Ьәйләгеч сүз төркемнәре: б-әйЯеХ теркәгеч. Модаль сүз төркемнәре: ымлык, кисәкчә, модаль сүзләр. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте.

## Синтаксис. Пунктуация

Синтаксисның төп берәмлекләре. Гади һәм кушма җөмләләрнең төрләре.

Текст һәм аның төзелеше, төп билгеләре*. Текст берәмлекләренең үзара бәйләнеше*.

Җөмләдә тыныш билгеләренең куелышы.

## Стилистика һәм сөйләм культурасы*

Стилистика фәне. Язма ьәм сөйләмә телгә хас үзенчәлекләр. Тел берәмлекләренең ьәм ярусларының үзара бәйләнеше. Татар телендә синонимия күренеше.

Күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнгән тел-сурәтләү чаралары (метафора, эпитет, метонимия һ. б.)

Сөйләм төзелешенә бәйле тел-сурәтләү чаралары (антитеза, риторик сорау, кабатлау ь.б.)

## Этнокультура өлкәсенә караган компетенция

Тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнеше. Татар халкының матди һәм рухи дөньясы чагылышы буларак тел. Сүз мәгънәсендә милли-мәдәни үзенчәлек чагылышы.

Татар теленең төрле милләтләр мәдәнияте белән бәйләнеше.

Аралашуның төрле өлкәләренә караган сөйләм этикеты нормалары һәм аларны урынлы куллану.